ГЛАВА
Салаушского сельского поселения
Агрызского муниципального района
Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Салагыш авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

29.10.2024 Салагыш авылы № 4

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Салагыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Мәдияр авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге Уставының 14 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е :

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Салагыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Мәдияр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 нче елның 11 нчы ноябрендә 14 сәгать 00 минутына билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2025 нче елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының “Салагыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Мәдияр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия армиясе сафларында хезмәт итәргә чакырылган затлардан һәм ирегеннән мәхрүм итү урыннарында торучы затлардан тыш, шулай ук хәрби операциядә катнашучылар (хәрби хезмәткәрләр, контрактлар буенча, ирекле яшәүче гаиләләр әгъзаларын һәм аларның ата-аналары (балигъ булган әгъзаларын) түләүдән азат итеп, калган һәр кешедән 1000 күләмендә үзарасалым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу,торак пункт

урамнарын кардан чистарту, дизель ягулыгы һәм май сатып алу, тракторчының эшенә шартнамә буенча түләү).

2. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау һәм электр энергиясен җиһазлар (электр товарлары һәм урам яктырту лампалары сатып алу) тапшыруны гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Мәдияр ав., Чишмә ур., 29 нче йорт янындагы мәйданчык адресы буенча гражданнар җыенын уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Салагыш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы М.М.Мөхәммәдиев